**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422650, пгт. Рыбная Слобода,
ул. Ленина, дом 48

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422650, Балык Бистәсе,
Ленин урамы, 48 нче йорт

Тел.: (84361) 22113, факс: (84361) 23012, e-mail: balyk-bistage@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

31.05.2016 Балык Бистәсе штп. № 80пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 20 гыйнварындагы 38п номерлы карары белән расланган «2015-2020 елларга Балык Бистәсе муниципаль районының коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру» муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнехановның 2016 елның 1 апрелендәге 18277 - МР номерлы күрсәтмәсен үтәү йөзеннән, Россия Федерациясе Президентының «2016-2017 елларга Коррупциягә каршы тору милли планы турында» 2016 елның 1 апрелендәге 147 номерлы Указы нигезендә карар бирәм:

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 20 гыйнварындагы 38пи номерлы карары белән расланган «2015-2020 елларга Балык Бистәсе муниципаль районының коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру» муниципаль программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

"2015-2020 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру" муниципаль программасының максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм программа чаралары буенча финанслау» кушымтасында:

"Бурыч 1” бүлеген түбәндәге эчтәлекле 1.7 – 1.13 пунктлары белән тулыландырырга:

| | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «1.7. Коррупциягә каршы тору максатларында билгеләнгән тыюларны, чикләүләрне һәм таләпләрне үтәмәгән очракта, законнарда каралган юридик җаваплылык чараларын куллануны контрольдә тотуны тәэмин итү | Балык Бистәсе муниципаль районы Советы (килешү буенча), Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты | 2016 - 2020 ел-лар | Балык Бистәсе муници-паль районының эчке контрольне һәм коррупция-гә каршы механизмны кадрлар сәясәтенә кертмәгән ММИ өлеше-процент | 94 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | - | - | - | - | - | - |
| 1.8.Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль хезмәте вазыйфаларын биләүче затларның мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау һәм җайга салу буенча эш алып бару юлы белән муниципаль хезмәттә мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау һәм җайга салу турындагы закон таләпләрен үтәүне тәэмин итү (күрсәтелгән таләпләрне үтәмәгән очракта, хәбәрдарлык бирергә һәм әлеге таләпләрне бозган затларга законнарда каралган юридик җаваплылык чараларын кулланырга) | Кадрлар хезмәтенең коррупцион һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи заты | 2016 - 2020 ел-лар | | | | | | | | | - | - | - | - | - | - |
| 1.9.Устав бурычы булып коррупциягә каршы торуда катнашу, шулай ук Балык Бистәсе муниципаль районы | Балык Бистәсе муниципаль районы Советы | 2016 - 2020 ел- | | | | | | | | | - | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Иҗтимагый советы һәм гражданлык җәмгыяте институтлары катнашында коррупциягә каршы тору максатларында билгеләнгән тыюларны, чикләүләрне һәм таләпләрне, шул исәптән бүләкләр алуга, башка түләүле эшләрне башкаруга кагылышлы тыюларны, чикләүләрне һәм таләпләрне үтәү буенча оештыру, аңлату һәм башка чаралар эшләү тора., коррупциячел хокук бозулар кылуга тарту максатларында мөрәҗәгатьләр турында хәбәр итү бурычы | (килешү буенча), Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты, Балык Бистәсе муниципаль районының Иҗтимагый советы (килешү буенча); Балык Бистәсе муниципаль районының иҗтимагый берләшмәләре (килешү буенча) | лар | | | | | | | | | | | | | | |
| 1.10. Балык Бистәсе муниципаль районында коррупциягә каршы көрәш буенча эшне координацияләү Комиссиясе утырышында муниципаль хезмәттә мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау һәм җайга салу турындагы закон таләпләрен үтәүнең торышы һәм аны камилләштерү чаралары турындагы мәсьәлә буенча ел саен фикер | Балык Бистәсе муниципаль районы Советы аппараты (килешү буенча); Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты | 2016 - 2020 ел-лар | | | | | | | | | - | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| алышуны тәэмин итү | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 1.11. Балык Бистәсе муниципаль районында коррупциягә каршы көрәш буенча эшне координацияләү комиссиясе эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру буенча чаралар күрү | Балык Бистәсе муниципаль районы Советы аппараты (килешү буенча); Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты, муниципаль учреждениеләр җитәкчеләре (килешү буенча) | 2016 - 2020 ел-лар | | | | | | | | | - | - | - | - | - | - |
| 1.12.Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары алдына куелган бурычларны үтәү өчен оешмалар һәм учреждениеләрдә коррупцияне кисәтү буенча эш алып бару | Балык Бистәсе муниципаль районы Советы аппараты (килешү буенча); Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты, Балык Бистәсе муниципаль районы башлыгының коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча ярдәмчесе (килешү буенча) | 2016 - 2020 ел-лар | | | | | | | | | - | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1.13. Муниципаль хезмәткәрләрдә коррупциягә тискәре караш формалаштыру буенча эш үткәрү | Кадрлар хезмәтенең коррупцияне профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи заты-район башлыгының коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча ярдәмчесе (килешү буенча) | 2016 - 2020 ел-лар» | | | | | | | | | - | - | - | - | - | - |

Бурыч 6» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Бурыч 6. Җирле үзидарә органнарының муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алганда ачыклыкны, намуслы конкуренцияне һәм объективлыкны тәэмин итү, муниципаль мөлкәтне куллану нәтиҗәлелеген арттыру»;

" Бурыч 6" бүлегенә түбәндәге эчтәлекле 6.3 пунктын өстәргә

| | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «6.3.Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә «Халык инвентаризациясе» акциясен үткәрү һәм ачыкланган бозуларны кисәтү һәм аларның нәтиҗәләрен бетерү буенча чаралар кūрү | Балык Бистәсе муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәт-ләре палатасы | 2016 - 2020 еллар» | | | | | | | | | - | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | (килешү буенча);<br>Балык Бистәсе муниципаль районы составына керүче җирлекләр-нең башкарма комитетлары (килешү буенча) | | | | | | | | | | | | | | | |

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru веб-адресы буенча, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче Р.Х.Хәбибуллин